СОВЕТ
НУРЛАТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НОРЛАТ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ                                   КАРАР

10 июль 2025 ел                    Норлат ав.                    №203

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыру турында.

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» № 131 – ФЗ Федераль законы Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районының Норлат авыл җирлеге Советы

карар итте:

1. Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшырырга:

- җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын паспортлаштыру.

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Норлат авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендәге Татар Ислам авылына мәктәп автобусы маршруты өчен керү кесәсен урнаштыру.

2. Норлат авыл җирлеге башкарма комитетына җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3. порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм шулай ук түбәндәге адреслар буенча: Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Норлат авылы, М.Фәйзуллин ур., 17 йорт

(«Идел Аръягы» ҮКС бинасы), Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Норлат авылы, Гагарин ур., 46 йорт (җирлек администрациясе бинасы) мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Норлат авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе И.М.Саттаров